# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**14.11.2025 ел** **№2**

2025 елның 20 мартындагы № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "Аю авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Дружба торак пунктында халык җыены

## КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә, 1,2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, МХОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, МХОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күпбалалы гаиләләрдән тыш.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
1) Дружба торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).
2) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булып саналмаган һәйкәлләрне урнаштыру, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (бакчачы Костин һәйкәлен ремонтлау) Дружба торак пунктында.

3..Әлеге карарны Аю авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru).

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл җирлеге башлыгы ____________ А.М.Галимов